РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 29 октябре г. Буинск № 87-п

Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарында таралышы чикләнгән хезмәт мәгълүматы белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Буа муниципаль районы башлыгының 2018 елның 18 апрелендәге 33-п номерлы «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарында таралышы чикләнгән хезмәт мәгълүматлары белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган, Буа муниципаль районының җирле үзидарә органнарында таралышы чикләнгән хезмәт мәгълүматы белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.7 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Таралышы чикләнгән хезмәт мәгълүматын үз эченә алган документларның булу-булмавын тикшерү җитәкче боерыгы белән билгеләнә торган комиссия тарафыннан елга бер тапкыр үткәрелә. Комиссия составына таралышы чикләнгән хезмәт мәгълүматлы документларны исәпкә алу һәм саклау өчен җаваплы хезмәткәрләр: Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитет эшләре идарәчесе , Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эшләре буенча ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру һәм мәгълүматны яклау бүлегенең баш белгече кертелә. Тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, алар төзелгән көннән алып өч көн эчендә барлык комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Комиссия рәисе итеп, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе билгеләнә. Комиссиянең барлык әгъзалары да ел саен үткәрелә торган тикшерүне үткәрү максатыннан, "Хезмәттә файдалану өчен" дигән тамгалы документлар белән танышырга хокуклы.»;

1.2. 2.9 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. «Хезмәттә файдалану өчен» тамгасы язылган югалган документларга,

эшләргә һәм басмаларга, югалган көннән соң ике көн эчендә тиешле акт төзелә, аның нигезендә исәпкә алу журналларында тиешле билгеләр ясала.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Башлыгы Р.Р. Камартдинов